Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Күгәрчен авыл җирлеге Советы

КАРАР № XIII-1

Күгәрчен авылы 2024 елның 23 декабре

2026 елга һәм 2027 һәм 2026еллар план чорына Балык Бистәсе муниципаль районы Күгәрчен җирлеге бюджеты турында

2003 елның 6 октябрендәге “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 131-ФЗ номерлы Федераль законның 35 маддәсе 10 өлешенең 2 пункты, Россия Федерациясе Бюджет кодексының 12, 14, 15 маддәләре, Татарстан Республикасының 2004 елның 28 июлендәге “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 45-ТРЗ номерлы Законының 22 маддәсе 8 өлешенең 2 пункты, ТР Балык Бистәсе муниципаль районы Күгәрчен авыл җирлеге Уставының 19 маддәсе 2 өлешенең 3 пункты һәм 70, 71 маддәләре нигезендә ТР Балык Бистәсе муниципаль районы Күгәрчен авыл җирлеге Советы КАРАР БИРӘ:

**1 маддә.**

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күгәрчен авыл җирлегенең 2025 елга бюджетының төп сыйфатламаларын расларга:

1) Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күгәрчен авыл җирлеге бюджеты керемнәренең гомуми күләме 6417.18 мең сум;

2) Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күгәрчен авыл җирлеге бюджеты чыгымнарының гомуми күләме 6417.18 мең сум;

3) Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күгәрчен авыл җирлеге бюджеты кытлыгы 0 сум.

2. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күгәрчен авыл җирлегенең 2026 елга һәм 2027 елга бюджетының төп сыйфатламаларын расларга:

1) Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күгәрчен авыл җирлегенең 2026елга керменең фаразланган гомуми күләме 6602.3, 2027 елга – 6898.1 мең сум;

2) Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күгәрчен авыл җирлегенең 2026елга бюджет чыгымнарының гомуми күләме 6602.3 мең

сум, шул исәптән шартлы рәвештә расланган чыгымнар 160.0 мең сум, 2027 елга алар тиңдәшле рәвештә 6898,1 мең сум һәм 334.5 мең сум;

3) Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күгәрчен авыл җирлегенең 2025 елга бюджеты кытлыгы 0 сум, 2026 елга –0 сум.

3. 2025 елга, 2026 һәм 2027 еллар план чорына Балык Бистәсе муниципаль районы Күгәрчен авыл җирлеге бюджеты кытлыгын финанслау чыганакларын 1 кушымтага ярашлы рәвештә расларга.

**2 маддә.**

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күгәрчен авыл җирлегенең 2026 елның 1 гыйнварына булган торышы буенча бурыч йөкләмәләре буенча эчке үзидарәлек бурычының югары чиген 0 сум, шул исәптән үзидарәлек гарантияләре буенча 0 сум күләмендә расларга.

2. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күгәрчен авыл җирлегенең 2027 елның 1 гыйнварына булган торышы буенча бурыч йөкләмәләре буенча эчке үзидарәлек бурычының югары чиген 0 сум, шул исәптән үзидарәлек гарантияләре буенча 0 сум күләмендә расларга.

3. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күгәрчен авыл җирлегенең 2028 елның 1 гыйнварына булган торышы буенча бурыч йөкләмәләре буенча эчке үзидарәлек бурычының югары чиген 0 сум, шул исәптән үзидарәлек гарантияләре буенча 0 сум күләмендә расларга.

**3 маддә**. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күгәрчен авыл җирлеге бюджетында керемнәрнең фаразланган күләмнәрен 2025 елга, 2026 һәм 2027 еллар план чорына 2 кушымтага ярашлы рәвештә игътибарга алырга.

**4 маддә.**

1.2025 елга, 2026 һәм 2027 еллар план чорына бюджет чыгымнары классификациясенең идарәчелек (тармак) структурасына, бүлекләр һәм бүлекчәләре, максатчан маддәләре һәм чыгымнар төркемнәре буенча бюджет ассигнованиеләре бүленешен 3 кушымтага ярашлы рәвештә расларга.

2.2025 елга, 2026 һәм 2027 еллар план чорына бюджет чыгымнарының ведомоство структурасын 4 кушымта нигезендә расларга.

3.Балык Бистәсе муниципаль районының Күгәрчен авыл җирлеге бюджетының 2025 елга гавами норматив йөкләмәләрне үтәүгә җибәрелә торган бюджет ассигнованиеләренең гомуми күләмен 0,00 мең сум һәм 2026 елның план чорына 0,00 мең сум, 2027 елга 0,00 мең сум күләмендә расларга.

**5 маддә.**

1. Балык Бистәсе муниципаль районы бюджетыннан җирлекләрнең бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә алына торган дотацияләрнең күләмен 2025 елга 5425.3 мең сум, 2026 елга 5582,9 мең сум, 2027 елга 5861,3 мең сум итеп расларга

Балык Бистәсе муниципаль районы бюджетыннан җирлекләр бюджетларының тигезлеген тәэмин итү буенча чараларга ярдәм итүгә җирлекләр бюджетына дотацияләр күләмен 2024 елга 25,84 мең сум, 2025 елга 24.85 мең сум, 2025 елга 8.66 мең сум итеп расларга.

**6 маддә.**

1. Хәрби комиссариатлар булмаган территорияләрдә башлангыч хәрби исәпне гамәлгә ашыру буенча вәкаләтләрне тормышка ашыруга җирлекләр бюджетына Балык Бистәсе муниципаль районы бюджетыннан алына торган субвенцияләр күләмен 2025 елга 182,98 мең сум, 2026 елга 200.1 мең сум, 2027 елга 207.3 мең сум итеп расларга.

7 маддә.

1. 2025 елда, 2026 һәм 2027 еллар план чорында Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органнары бюджет өлкәсе учреждениеләре һәм бүтән оешмаларының үзидарәлек хезмәткәрләре һәм работниклары санын, шулай ук аларны тотуга чыгымнарны арттыруга китерә торган карарлар кабул итәргә хаклы түгелләр.

8 маддә.

1.Татарстан Республикасы Финанслар министрлыгының казначылык органнары төзелгән килешүләр нигезендә Күгәрчен авыл җирлеге бюджетын үтәү буенча аерым функцияләрне гамәлгә ашыралар.

9 маддә.

Товарлар белән тәэмин итүгә, эшләр башкаруга, хезмәтләр күрсәтүгә Балык Бистәсе муниципаль районы Күгәрчен авыл җирлеге исеменнән төзелгән муниципаль контрактлар буенча түләү өчен бирелгән 2025 елның 1 гыйнварына калган акчалары, әлеге муниципаль контрактлар шартлары нигезендә 2024 елда түләнергә тиешле бюджет ассигнованиеләренең файдаланылмый калган суммасыннан артмаган күләмдә 2025 елда, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күгәрченм авыл җирлеге Башкарма комитеты тарафыннан
тиешле карар кабул ителгән очракта, күрсәтелгән максатларга тиңдәшле бюджет ассигнованиеләрен арттыру өчен җибәрелә.

10 маддә.

1. Әлеге карар 2025 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

11 маддә.

1. Карарны түбәндәге адрес буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында: Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе муниципаль районы, Күгәрчен авылы, Зәитовлар урамы, 1А йорты, һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-

телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Күгәрчен авыл җирлеге башлыгы,
җирлек Советы рәисе А.Т.Сафин